ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 408

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«19» декабрь 2018 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2016 елның 12 февралендәге 53 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салуга карата таләпләр үтәлеше буенча Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында законнар үтәлешен тикшереп торуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы указы, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы указы кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2016 елның 12 февралендәге 53 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салуга карата таләпләр үтәлеше буенча Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе комиссиясе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 15.6 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

«15.6. Әлеге Нигезләмәнең 15.1, 15.3 һәм 15.4 пунктларында каралган дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрләмәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм мәнфәгатьле оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 22, 23.3, 24.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.».

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А. Крайнов